РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 31 » 08 2023 г. №1324

«2020-2025 елларга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының авыл территорияләрен комплекслы үстерү» муниципаль программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 14 августындагы 599 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә “2013-2025 елларга авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу турында» дәүләт программасын раслау турында” 08.04.2013 № 235 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында” 25.04.2020 № 330 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү” дәүләт программасын гамәлгә ашыру һәм «Татарстан Республикасында авыл территорияләрен комплекслы үстерү” Россия Федерациясе дәүләт программасын гамәлгә ашыру турында» 14.05.2020 № 387 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, муниципаль берәмлек бюджетына субсидияләр бирү максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. «2020-2025 елларга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының авыл территорияләрен комплекслы үстерү» муниципаль программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 14 августындагы 599 номерлы

карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Программаның финанс белән тәэмин итү нигезенә һәм чыганакларына кагылышлы позициядә Программаның паспортында:

п.1, а) пунктчасы Авыл территорияләрендә яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшырту - 4 465 188,00 сум саннарын, 6 881 968,80 сум саннарына алмаштырырга.

б) Торак урыны наем шартнамәсе буенча бирелгән торак төзелеше 4 034 784,00 сум саннарын, 7 394 016,00 сум саннарына алмаштырырга.

в) Җәяүлеләр өчен коммуникацияләр оештыру - 3 847 500,00 сум саннарын, 7 087 500,00 сум саннарына алмаштырырга.

п.2 пунктча а) Авыл территорияләрендә яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшырту - 2 864 796,00 сум саннарын, 3 431 695,20 сум саннарына алмаштырырга.

б) Торак урыны наем шартнамәсе буенча бирелгән торак төзелеше 2 477 856,00 сум саннарын, 3 265 824,00 сум саннарына алыштырырга.

в) җәяүлеләр өчен коммуникацияләр оештыру 902 500,00 сум саннарын 1 662 500,00 сум саннарына алмаштырырга.

- п.3, б) пунктчасы - Торак урыны наем шартнамәсе буенча бирелгән торак төзелеше - 81 408,00 сум саннарын 133 248,00 сум саннарына алмаштырырга.

в) Җәяүлеләр өчен коммуникацияләр оештыру - 47 500 сум саннарын 87 500,00 сум саннарына алмаштырырга.

п.4, а) пунктчасы - Авыл территорияләрендә яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшырту - 2 447 136,00 сум саннарын 3 725 856,00 сум саннарына алмаштырырга.

б) Торак урыны наем шартнамәсе буенча бирелгән торак төзелеше - 1 546 752,00 сум саннарын, 2 531 712,00 сум саннарына алмаштырырга.

в) җәяүлеләр өчен коммуникацияләр оештыру 1 988 242,86 сум саннарын 3 662 528,58 сум саннарына алмаштырырга.

2. «Муниципаль программа чаралары исемлеге» Программасы паспортының 7 пунктында «Тукай урамы, Байлар авылы буенча җәяүлеләр өчен тротуар төзү» 8 юлын һәм «Ютазы урамы, Байрәкә авылы буенча җәяүлеләр өчен тротуар төзү» 9 юлын өстәргә:

| т/б | Кече программа ведомство максатчан программасы) чарасы, төп чара исеме | Җаваплы башкаручы | Гамәлгә ашыруның башлану һәм тәмамлану вакыты | Турыдан-туры көтелә торган нәтиҗә (кыскача тасвирлама) | Муниципаль программаның (ярдәмче программаларның) максатчан күрсәткечләре (индикаторлары) белән элемтә |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 8 | Ютазы муниципаль районының Байлар авылы Тукай урамы буенча җәяүлеләр өчен тротуар төзү | Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары | 2023 | «Җәяүлеләр коммуникацияләрен оештыру (тротуарлар төзү 386 метр)» юнәлеше буенча авыл территориясен төзекләндерү (Проект). Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү. | Уңайлы шартлар тәэмин итү |
| 9 | Ютазы муниципаль районының Бәйрәкә авылы Ютазы урамы буенча җәяүлеләр өчен тротуар төзү | Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары | 2023 | «Җәяүлеләр коммуникацияләрен оештыру (тротуарлар төзү 386 метр)» юнәлеше буенча авыл территориясен төзекләндерү (Проект). Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү. | Уңайлы шартлар тәэмин итү |

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы составында http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга .

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина

С.Р. Сәетгәрәева
2-42-05